ЧӘРШӘМБЕ
10
МАРТ
1943 ел.
№ 56 (6778)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

БӨТЕН КӨЧЕБЕЗНЕ—ФРОНТКА, ГЕРОИК КЫЗЫЛ АРМИЯБЕЗГӘ ЯРДӘМГӘ! ДАНЛЫКЛЫ КЫЗЫЛ ФЛОТЫБЫЗГА ЯРДӘМГӘ!

Эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар, колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар һәм барлык хезмәт ияләре! Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавына сөекле Кызыл Армиябез өчен тагын да күбрәк танклар, самолетлар, орудиеләр, минометлар, снарядлар, миналар, пулеметлар, автоматлар, винтовкалар җитештерү белән, фронтка күбрәк азык җитештерү белән җавап бирик!

МОСКВА, КРЕМЛЬ.

Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Совет халкы шатлыклы көннәр кичерә. Сезнең зирәк җитәкчелегегездә батыр Кызыл Армия дүртенче ай инде җиңүле һөҗүмне дәвам иттерә, явыз дошманны тар-мар итә, шәһәрләребезне һәм авылларыбызны немец-фашист оккупантлардан чистарта. Орденлы Татарстан АССР эшчеләре, колхозчылары, интеллигенциясе, героик Кызыл Армиянең гүзәл хәрби уңышлары белән рухланып, үзләренең фронтка ярдәмнәрен көчәйтергә омтылып, «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә моннан элек җыелган 100 миллион сум өстенә «Советлар Татарстаны» исемле сугыш самолетлары эскадрильялары төзелешенә үзләренең саклык акчаларыннан Дәүләт банкысына тагын 100 миллион сум акча керттеләр. Шулардан 22 миллион сумын Казан шәһәре эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре кертте. Танклар колоннасына һәм авиация эскадрильясына средстволар җыю ватанга мәхәббәт хисе белән тулган, аның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен бөтенесен бирергә хәзер торучы совет кешеләренең куәтле патриотизм хәрәкәте сыйфатында үтте.

Ватан сугышы башланганнан бирле Татарстанның хезмәт ияләре, Сезнең, иптәш Сталин, бөтенесен фронт өчен бирергә чакыруыгыз белән рухланып, оборона фондына 39 миллион сум акча һәм 12 миллион сумлык дәүләт заемнары облигацияләре җыйдылар, фронтовикларга 29 миллион сумлык бүләк җибәрделәр. Шулар арасында туену продуктлары гына да 33.270 пот җибәрелде. Алар фронтка 23.000 данә кыска тун, 54.000 пар киез итек, 59.000 пар телогрейка һәм чалбар, 106.000 пар җылы эчке кием һәм башка төрле күп җылы киемнәр җибәрделәр. Шуның өстенә республиканың колхозчылары 61.141 килограмм йон һәм 97.320 данә сарык тиресе җыйдылар.

Республика комсомолецлары һәм яшьләре үз средстволарына 3 сугыш самолетлары эскадрильясы төзеделәр һәм Кызыл Армиягә тапшырдылар.

Татарстанның партия һәм җәмәгать оешмалары немецлар оккупациясеннән азат ителгән районнарга, шулай ук Кызыл Армия сугышчыларының һәм командирларының семьяларына ярдәм күрсәтү эшен җәеп җибәрделәр. Февраль аенда Казан шәһәрендә 17.747 фронтовикның семьясына кирәкле ярдәм күрсәтелде: аларга 11.063 кубометр утын, 10.122 пар костюм һәм эчке киемнәр, 9.199 пар киез итек һәм күн аяк киеме, 5.458 метр мануфактура, 37.430 килограмм төрле яшелчә, 546.202 сум акча бирелде, фронтовикларның 1.990 баласы балалар ашханәсенә беркетелде.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән Сезнең тарихи приказыгыз бөтен совет халкы өчен сугышчан эш программасы булып тора.

Дошманны тәмам тар-мар итү көнен якынайту өчен, хезмәт сөюче Татарстан халкының илебездәге барлык хезмәт ияләре белән берлектә, фронтка үзләренең ярдәмнәрен тагын да көчәйтәчәкләренә Сезне ышандырабыз, кадерле Иосиф Виссарионович.

Сезгә, сөекле атабыз Иосиф Виссарионович, озак, бик озак еллар яшәү һәм сәламәтлек телибез.

ВКП (б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре КОЛЫБАНОВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Татарстан АССР Совнаркомы председателе ГАФИЯТУЛЛИН.

КАЗАН.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш КОЛЫБАНОВКА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш ДИНМӨХӘМЕТОВКА

Татарстан АССР Совнаркомы председателе иптәш ГАФИЯТУЛЛИНГА

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының „Татарстан колхозчысы" исемле танклар колоннасы төзелешенә моннан элек кертелгән 100 миллион сумнан тыш өстәмә рәвештә „Советлар Татарстаны" исемле сугыш самолетлары эскадрильялары төзелешенә 100 миллион сум акча, Кызыл Армия өчен бүләкләр һәм җылы киемнәр җыйган, фронтовиклар семьяларына ярдәм күрсәткән хезмәт ияләренә минем туганлык сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

ПРОМЫШЛЕННОСТЬНЫҢ, АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ, ФӘННЕҢ, ТЕХНИКАНЫҢ ҺӘМ СӘНГАТЬНЕҢ АЛДЫНГЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫН ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

Халыкара коммунистик хатын-кызлар көне—8 нче мартны истә калдыру теләге белән промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларыннан түбәндәгеләрне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләргә:

1. Мария Семеновна **Абакумованы**—Н-че завод эшчесе.
2. Марганиса Ибраһим кызы **Аблакованы**—Татарстан АССР Юстиция Халык Комиссариатының өлкән ревизоры.
3. Александра Архиповна **Абрамованы**—Н-че заводның техник-контроль бүлеге бригадиры.
4. Вера Владимировна **Агафонованы**—Казандагы 1 нче инфекция больницасы ассистенты.
5. Антонина Алексеевна **Александрованы**—Автогараж җиһазлары заводының диспетчеры.
6. Сара Хәсән кызы **Айгистованы**—Казан экспериментал медицина институты лаборанткасы.
7. Надежда Николаевна **Алексееваны**—Н-че завод конструкторы.
8. Татьяна Николаевна **Алексапольскаяны**—Чистайдагы суднолар ремонтлау заводы токаре.
9. Хәбибә Шакир кызы **Әльмөхәмәтованы**—«Азат хатын» промартеле председателенең урынбасары.
10. Гайшә **Әминованы**—Ютазы районы, Куйбышев исемендәге колхозның умартачысы.
11. Анастасия Павловна **Андрееваны**—Казандагы 1 нче инфекция больницасының медицина сестрасы.
12. Елизавета Григорьевна **Андрееваны**—Алабуга районы, Гассар исемендәге колхоз члены.
13. Таисия Ивановна **Антипинаны**—Н-че завод эшчесе.
14. Ксения Николаевна **Антонованы**—«Спартак» комбинатының кисүчесе.
15. Евдокия Федоровна **Афанасьеваны**—Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының председатель урынбасары.
16. Роза Кәбир кызы **Әхмәдуллинаны**—врач, эвакогоспиталь начальнигы.
17. Екатерина Алексеевна **Арефьеваны**—«Великан» промартеленең производство мөдире.
18. Хәмдия **Ахватованы** — «Спартак» комбинаты эшчесе.
19. Хәерниса **Баһаветдинованы**—«Швеймехпром» промартеленең скорнячкасы.
20. Евстолия Васильевна **Багдериннаны**—ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы.
21. Наимә Рәхим кызы **Байтерәкованы**—врач, эвакогоспиталь бүлеге начальнигы.
22. Екатерина Семеновна **Байцерованы**—ВЛКСМ ның Бөгелмә райкомы секретаре.
23. Екатерина Константиновна **Балахничеваны**—«Татполиграф» типографиясенең хәреф җыючысы.
24. Евдокия Ивановна **Барбутьконы** — Казан шәһәре, ВКП(б) ның Свердловск райкомының кадрлар буенча секретаре.
25. Полина Борисовна **Бассны**—Н-че завод лаборанткасы.
26. Хәмидә Баян кызы **Баянованы**—Минзәлә районы, Маткавыш МТС ы тракторчысы.
27. Дарья Никитична **Белозерцованы**—ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдиренең урынбасары.
28. Халидә Нажи кызы **Бикмуллинаны**—Н-че завод эшчесе.
29. Газизә **Бикмөхәмәтованы**—Казандагы 1 нче инфекция больницасы санитаркасы.
30. Галия **Биктаһированы**—Дөбьяз районы, Юртыш МТС ы тракторчысы.
31. **Гайнисафа Биляеваны**—Беренче Май районы, Пушкин исемендәге колхозның бозаулар караучысы.
32. Рәхимә Билялетдин кызы **Билялетдинованы**—«Кызыл Шәрык» заводының цех бригадиры.
33. Анна Борисовна **Болякинаны**—Мамадыш элемтә конторасының матбугатны тарату һәм экспедицияләү бүлеге мөдире.

(Ахыры бар).

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕКТӘ ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮДӘ БОЛЬШЕВИСТИК АГИТАЦИЯ

С. ГАФАРОВ.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының пропаганда буенча секретаре

• • •

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның 23 нче февральдәге тарихи приказы бөтен Совет илендә гаять зур патриотик күтәрелеш чыгарды. Героик Кызыл Армиянең һөҗүме турында һәм аның яңа уңышлары турында ватан сугышы фронтларыннан шатлыклы хәбәрләр килеп торуда дәвам иткән бу көннәрдә совет кешеләренең хезмәткә һәм көрәшкә булган омтылышы чиксез арта. Большевистик сүзнең бөек көчен барлык хәрби-хуҗалык бурычларны уңышлы итеп хәл кылуга, социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерүгә юнәлдерергә тиешле агитаторларның роле хәзер аеруча нәтиҗәле һәм мактаулы булып әверелә.

Язгы чәчү якынлаша. Безнең колхозларыбызның, совхозларыбызның, МТС ларның һәм аларның җитәкчеләренең сугышчан бурычы, республикадагы партия, совет, комсомол һәм хуҗалык оешмаларының бурычы—алдагы кыр эшләренә үрнәкле рәвештә һәм үз вакытында әзерләнеп, 1943 нче елда чын-чыннан югары уңыш алу өчен барлык мөмкинлекләрне тудырудан гыйбарәт. Чәчүгә әзерлектәге һәм аны үткәрүдәге барлык оештыру, хуҗалык һәм агротехника бурычларын кешеләр, кадрлар хәл итәчәк. Менә шуның өчен дә кадрлар белән эшләү мәсьәләсе барлык партия, совет һәм комсомол оешмаларының игътибар үзәгенә куела. Бу исә хәзер үк колхозларда агитация-масса һәм пропаганда эшен киң җәелдерергә, колхозчыларны һәм колхозчы хатын-кызларны, МТС һәм совхоз работникларын язгы чәчүгә яхшылап әзерләнү һәм үткәрүгә тупларга кирәк дигән сүз. Һәм бу эштә, бик хаклы рәвештә, безнең авыл агитаторларының роле гаять зур. Югары уңыш өчен көрәшнең, язгы чәчүгә үз вакытында һәм югары сыйфатлы итеп әзерләнүнең әһәмиятен хезмәт ияләренә аңлатуда агитация һәм пропаганда эшенең барлык формаларын нәтиҗәле итеп файдаланырга кирәк. Безнең агитаторларыбыз агитация-пропаганда һәм массакүләм политик эшнең барлык средстволары белән кешеләрдә аларның үзләренә тапшырылган эшкә карата югары җаваплылык тойгыларын армый-талмый тәрбияләргә тиешләр.

Сугыш үзенең нормаларын һәм темпларын таләп итә, сугыш кешеләргә таләпчәнлекне арттыра, ул һәрбер работникның көче һәм сәләте тулысынча файдаланылган булуны сорый. Агитаторлар, дәүләт тарафыннан колхозга бирелгән заданиенең какшамас закон икәнлеген, аны тулысынча һәм төгәл билгеләнгән срокларда үтәргә кирәк икәнлекне хезмәт ияләренә аңлатырга тиешләр. Социалистик ярыш буенча колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар үз өстенә алган йөкләмәләрен илгә һәм фронтка биргән ант итеп аңласыннар. Агитаторлар менә шуңа ирешергә тиешләр.

Агитаторлардан, пропагандистлардан, лекторлардан һәм докладчылардан барлык колхозчыларга бары тик югары дисциплиналылык һәм оешканлык булганда гына аларның язгы чәчүгә уңышлы итеп әзерләнү һәм аны үткәрүгә ирешә алачакларын тирәнтен һәм төшенерлек итеп аңлату таләп ителә. Чәчүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча социалистик ярышны киң җәелдерү, колхозларның, аерым бригадаларның һәм звеноларның язга әзерлекләрен масса төсендә үзара тикшерүне оештыруда эшлекле катнашу—авыл агитаторларының намус эше. Бу эшне, ул барлык әзерлек эшләрен үз вакытында һәм үрнәк төстә тәмамлауга нәтиҗәле рәвештә ярдәм итсен өчен, аны югары политик дәрәҗәдә үткәрергә кирәк.

Большевистик агитация конкрет эчтәлекле булырга тиеш. Һәм безнең агитаторларыбыз орлыкларның торышы белән дә, авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт планының үтәлеше белән дә, агротехника чараларының дөрес үткәрелүе белән дә—ягъни, язга әзерлекнең барлык мәсьәләләре белән дә кызыксынырга тиешләр. Барлык колхозларда һәм бригадаларда гомуми җыелышлар үткәрергә, анда язгы чәчүгә әзерлекнең торышын җентекләп тикшерергә, барлык урыннарда да шул ук мәсьәләләргә багышлап стена газеталары һәм сугышчан листоклар чыгару эшен юлга салырга кирәк. Гомумән колхоз гына түгел, бәлки һәрбер кырчылык звеносы, аерым алганда һәрбер бригада чәчү кампаниясенә иң яхшы итеп әзерләнүне тикшерергә һәм конкрет план төзәргә тиеш.

Совет авылында, безнең бөтен илебездәге кебек үк, гаять зур патриотик күтәренкелек хөкем сөрә. Колхоз активының, партия һәм совет активының бурычы—бу күтәренкелеккә җитәкчелек итүдән, барлык чараларның үрнәк төстә үтәлүен тәэмин итүдән гыйбарәт. Республикабыздагы күп кенә колхозларның эш практикасы шуны күрсәтә ки, кешеләр белән политик эш яхшы һәм югары дәрәҗәдә үткәрелгән урыннарда—язгы чәчүгә әзерлек бурычлары да уңышлы хәл ителәләр. Менә Дөбьяз районының «Кызыл байрак» колхозы. Анда, хәрәкәтчән агитация алып бару, эшне оста итеп оештыру нәтиҗәсендә барлык авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт күптән тәмамланган, орлыклар чистартылган һәм аларның тишелешләре тикшерелгән, башка төрле агротехника чаралары да уңышлы үтәләләр.

Столбище районының «Память Ленина» авыл хуҗалыгы артеле агитаторлары да шулай ук язгы чәчүгә әзерләнүдә күп эш башкардылар. Монда, алдагы кыр эшләренә атларны әзерләү һәм аларны тәрбияләү буенча ярышның яхшы гына нәтиҗәләре бар. Агитаторлар, шулай ук, вак инвентарьга ремонт ясау буенча да ярыш оештырдылар. Бу колхозның һәрбер бригадасы, һәрбер звеносы үзенә конкрет социалистик йөкләмә алды һәм аларны уңышлы рәвештә үти.

Биектау районының Пушкин исемендәге һәм күп кенә башка колхозларындагы агитаторлар да яхшы нәтиҗәләргә ирешүләр. Алар ирешкән уңышларның «сере»—кешеләр белән оста итеп эш итүдә, большевистик, һөҗүмчән агитацияне актив рәвештә алып баруда.

Бу алдынгы агитаторларга ярдәм итү һәм аларның эш тәҗрибәсен башкаларга күчерү, аларның инициативасын һәрьяклап күтәрү һәм, бер үк вакытта, авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан һәм авыл интеллигенциясеннән яңа иптәшләрне политик эшкә тартып, агитаторлар кадрларын тулыландыру—ВКП(б) райкомнарының изге бурычы.

Агитация-масса эшендә уку өйләренең һәм колхоз клубларының роле гаять зур. Алар барлык урыннарда да колхозчыларны һәм колхозчы хатын-кызларны политик-тәрбияләү эшенең сугышчан үзәгенә әверелдерергә тиешләр.

1943 нче елда язгы чәчү вакытында безнең агитаторлар, гаять дәрәҗәдә җитди политик сынау үтәргә тиешләр. Агитаторлар, үзләре алдына куелган бурычларны намус белән үтәп, кырларда үзүзенне аямыйча эшләү үрнәген күрсәтеп, фронтка зур һәм җитди ярдәм итәрләр.

БОЛЬШЕВИСТИК СҮЗ—МАССАГА

Соңгы вакытларда Биектау район партия кабинеты, марксизм-ленинизм теориясен пропагандалау буенча үзенең эшен шактый яхшыртты.

Барлык башлангыч партоешмаларда партия тарихын өйрәнүнең торышы турында җыелышлар булды. «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» ның 8 нче бүлеге буенча парткабинет янында семинар һәм партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр өчен ике тапкыр теоретик конференция үткәрелде.

Район активы катнашы белән парткабинет янында консультантлар һәм лекторлар группасы системалы рәвештә эшли башлады. Лекторлар колхозларга чыгып лекцияләр, айга ике тапкыр агитколлектив җитәкчеләре белән семинарлар үткәреп баралар.

Хәзер агитаторлар колхозчылар арасында, иптәш Сталинның Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән чыгарылган приказын һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарларын аңлатуны җәеп җибәрделәр.

Д. СКВОРЦОВ.

Хатлар

Каһәрле дошманга төзәп,
Мин мылтык аткан чакта,
Гүя син патроннар салып
Торасың минем катта.

Сугышчы Марат Мифтахетдинов күңелле хисләргә бирелеп сөйләвеннән туктады да, гади тавыш белән:

— Бик дөрес. Язучы Фатих Кәрим үзе дә фронтта шул ул. Шуңа күрә сугышчының хисләре турында матур җырлый. Яратам мин аның шигырьләрен дип,—тагын сөйли башлады.

Ә шулай да, син еракта
Мин тик хатыңны күрәм,
Хатка язган сүзләреңне
Күзләрең итеп үбәм.

— Миңа шундый хат килми шул,—дип күңелсезләнеп, кинәт туктады.

— Сөйлә инде, сөйлә. Яза башлаганнар,—дип инде, килер әле,—дип шаяртышлар Маратны иптәшләре һәм:

— Сорыйбыз, сорыйбыз, дип алкышлый да башладылар. Нәкъ шушы вакытта землянка ишеге ачылды. Аннан иң элек бөркелеп салкын һава керде. Тышта буран улаган тавышы ишетелде. Шундый ыжгырып торган салкыннан керүгә дә карамастан, ишектән керүче кече лейтенант Сәйфинең йөзе якты, елмаюлы иде.

— Сугышчылар, безгә хат бар,—дияргә дә өлгерә алмады, аның артыннан ук икенче берәү атылып килеп керде дә, кече лейтенантның алдына ук килеп басты.

— Сезгә пакет бар,—дип кулындагы конвертны аңа бирде. Сугышта эшнең уңышын секундлар хәл итәләр. Нинди генә кадерле хат булса да, аны укырга вакыт юк иде инде. Сәйфи, декламация сөйли торган урынында әле дә басып торучы Маратка хатны бирде дә:

— Сугышчан задание бар. Шуны үтәгәч укырбыз, сакла,— диде.

Кич булгач, взводтагы сугышчылар тагын блиндажга җыелдылар. Батыр артиллеристлар үзләренең кадерле ял вакытларын хатны укуга багышладылар. Марат иртән декламация сөйләгән урынына басып, аны укый башлады.

Фронтта хат менә шулай кадерле. Аның турында җырлар җырлыйлар. Аның белән атакаларга баралар. Катлаулы сугыш заданиеләрен башкарганнан соң, землянкада, консерва савытыннан ясалган лампа яктысында, ул да булмаса шырпы кабызып торып, хатны кат-кат укыйлар. Үзләренең матур уйларын сөйләп җавап язалар.

Менә разведчик Мидхәтнең хатлар аша гына таныш дустына язган хаты.

«Мин хәзер генә дошман тылыннан разведкадан кайттым. Үземнең частемнан ерак булуыма карамастан, синнән хат көттем һәм аны күңелемнән укып йөрдем. Бүген кадерле хатны кулыма алдым. Ул миңа никадәр шатлык китерде. Авыр кичерешләр барысы да онытылды. Мин яңадан бәхетле һәм шат».

Хатның ахырында Мидхәт дусларча:

«Ә кая соң синең рәсемең? Ул минем йөрәк турымдагы кесәмдә йөргән хәлдә, немец еркычларны тар-мар итүдә турыдан-туры катнашсын иде»,—ди. Разведчик якын кешесенең рәсемен янында йөртәсе килә. Штурман-радист Вася Годуновның хаты аны тагын да ачыклый.

«Миңа еш кына махсус задание белән парашютта дошман тылына сикерергә туры килә. Команда булуга бик биеклектән очып баручы самолеттан парашютта сикереп, салкын һава дулкыннары арасында бер үзең каласың. Берничә секундка парашют ачылмый тора. Шул секундларда да синең күз алдыңа хатының һәм балаң килеп баса. Алар да минем белән бергә, яшен тизлегендә түбәнгә төшәләр шикелле тоела. Менә парашют ачыла. Шатлыктан кычкырып көлеп җибәрәсең. Куллар күкрәк кесәсендәге рәсемне барлап, капшап карыйлар. Ул иксез-чиксез күктә йөзгәндә дә сиңа юлдаш була. Теләсә нинди кыенлыкларны да җиңәргә, тапшырылган эшне кыю башкарырга көч бирә. Алар минем бөек илемнең азат кешеләре

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

МӨСЛИМ

МӨСЛИМ, 9 март. (Телефон буенча). «Дусай» колхозы членнары язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы игълан итеЛү белән үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алып кызу эшкә керештеләр. Чәчкечләргә, сабаннарга, культиваторларга ремонт тәгәлләнде. Чәчү орлыклары барлык культуралар буенча да җитәрлек әзерләнде. Орлыклар яхшы итеп тазартылган. Аларның тишелеше 97—98 процент. Кар тоту, көл һәм башка җирле ашламалар туплау планы 100 процентка үтәлде.

Р. ИБРАҺИМОВА.

БУА

БУА, 9 март. (Телефон буенча). «Ирек» колхозында язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы кызу темп белән бара һәм яхшы нәтиҗәләр бирә. Хәзер колхозчылар бодай, борчак, ясмык һәм карабодай орлыкларын тазарту эшләрен 20 нче мартка тәмамлау өчен тырышалар.

Машиналарга ремонт ясауны тәмамлау буенча да ашыгыч чаралар күрелде. Тагын 6 чәчү машинасына ремонт ясыйсы бар. Бу эшне Галиев һәм Гыймадиев иптәшләр үз өсләренә алдылар һәм 25 нче мартка тәгәлләргә сүз бирделәр.

Басуга тирес чыгару, җирле ашламалар туплау буенча һәрбер бригадага җаваплы аерым кешеләр беркетелде.

М. НУРЕТДИНОВА.

АРЧА

Язгы чәчүгә әзерлек эшләрендә «Сукачы» колхозы (председателе иптәш Сафина) Арча районында алдынгылар рәтендә бара. Бу колхозда югары сыйфатлы орлык әзерләүгә көздән үк нык әһәмият бирел килделәр. Орлыкларны соңгы тапкыр лабораториядә тикшерү аларның сыйфаты яхшы икәнлеген күрсәтте.

Язгы чәчү өчен кирәкле машиналарга һәм сбруйларга ремонт ясау да уңышлы үтте.

Агротехника чараларын үткәрү планы арттырып үтәлде. Мәсәлән, кар тоту планы 170 процентка, көл җыю планы—135 процентка үтәлде. Басуга 1.650 тонна урынына 2.560 тонна тирес чыгарылды.

Колхозчылар агротехниканы зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Моның өчен аерым түгәрәк бар. Түгәрәккә иптәш Мәрдәнова җитәкчелек итә.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.

СВОДКА.

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 5 нче МАРТЫНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	38. Кызыл йолдыз	76,4	75. Алексеевский	58,7
2. Чокалы	100,0	39. Норлат	76,2	76. Константиновка	57,7
3. Актаныш	100,0	40. Мәлки	76,0	77. Ромадан	57,5
4. Бөгелмә	100,0	41. Бондюг	75,6	78. Столбище	57,5
5. Нөркәй	100,0	42. Поповка	75,6	79. Иске Чишмә	56,8
6. Алга	100,0	43. Аксубай	75,0	80. Кама тамагы	56,7
7. Тымытык	100,0	44. Кызыл Чапчак	75,0	81. Арча	55,8
8. Алабуга	100,0	45. Чаллы	74,5	82. Питрәч	55,3
9. Тирсә	100,0	46. Балтач	73,1	83. Салман	55,3
10. Ишеево	100,0	47. Исәнбай	73,0	84. Кызыл юл	53,3
11. Чүпрәле	100,0	48. Калинин	72,0	85. Әхмәт	53,0
12. Дөбьяз	100,0	49. Куйбышев	71,9	86. Макыл	52,8
13. Яниль	100,0	50. Тәтеш	70,8	87. Зур Поляна	52,6
14. Саба	96,0	51. Баулы	70,4	88. Мизәлә	52,1
15. Мөрәле	91,5	52. Кичү	69,0	89. Морт	51,0
16. Юдино	90,0	53. Кәкре елга	68,9	90. Майдан	50,0
17. Юртыш	89,3	54. Тельман	68,0	91. Балык Бистәсе	50,0
18. Сарман	88,7	55. Әтнә	68,0	92. Карамалы	49,1
19. Октябрь	87,9	56. Шөгер	67,9	93. Казанбаш	48,5
20. Дәүләки	87,0	57. Буа	66,7	94. Мамадыш	48,4
21. Кадряк	86,5	58. Беренче Май	66,7	95. Үләк	47,1
22. Заинский	86,2	59. Яңа Чишмә	66,7	96. Тат. Ялтан	57,0
23. Зөя	85,7	60. Әлмәт	66,7	97. Трехозерский	45,3
24. Т. Тамак	84,6	61. Теләче	65,3	98. Ключи	44,8
25. Олы Карилә	84,0	62. Буденный	64,9	99. Әлки	44,6
26. Тархан	83,6	63. Черемуховский	64,8	100. Кузнечиха	44,4
27. Чүрибураш	83,0	64. Әлши	64,3	101. Чиябаш	44,4
28. Соколка	82,4	65. Рождественский	64,1	102. Иске Писмән	43,3
29. Акташ	81,0	66. Каргалы	63,3	103. Тат. Ходяш	41,7
30. Азин	81,0	67. Тәкәнеш	62,3	104. Биектау	39,6
31. Б. Матак	80,4	68. Чаллы	62,2	105. Чишмә	39,4
32. Чистай	80,4	69. Маткавыш	62,1	106. Кошкино	30,4
33. Иске Тимошкино	78,9	70. Солтан	61,8		
34. Кузайкино	78,2	71. Зирекле	61,5	БАРЛЫГЫ:	69,4
35. Чыбыклы	77,8	72. Ютазы	60,0		
36. Димитров	77,1	73. Мөслим (Чистай)	58,8	1943 нче елның	
37. Кукмара	76,8	74. Биләр	58,7	беренче мартына	66,9

АВТОРИТЕТ ТУРЫНДА

Моннан ике генә ел элек Куйбышев исемендәге колхоз турында Шөгер районында гына түгел, хәтта тирә-якта да дан яңгырый иде. Андагы үрнәк тәртип, оешканлык, тимердәй дисциплина, һәрбер эш тармагында хуҗаларча кайгыртучанлык бик күпләргә үрнәк булырлык иде.

Ләкин соңгы вакытларда бу колхозның эше бөтенләй башкача. Аның бер генә хуҗалык кампаниясен дә срогында үтәгәне юк. Ике ел рәттән 100 гектарга якын игене хәтта, бөтенләй җыелмый калган. Аның өстенә бик күп ашлык чертелгән. Үткән елгы көзге чәчү планы бары 78 процентка гына үтәлгән. Тунга сөрү планы да үтәлмәгән. Терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планы өзелгән. Яз якынлашып килә, ә биредә җигәргә сбруйлар юк. Кышкы агротехника чараларын үткәрү үз агымына куелган.

Мондый хурлыклы хәлнең сәбәпләре нәрсәдә соң? Барыннан да элек, колхоз җитәкчеләренең ватан алдындагы, фронт алдындагы җаваплылык хисләрен югалтуларында, колхозчылардагы политик-производство активлыгына җитәкчелек итмәүләрендә.

Бу колхоз җитәкчеләре бөтен гаепне колхозчылар өстенә аудармакчы, сугыш вакыты кыенлыкларына кайтарып калдырмакчы булалар.

Ватан сугышы колхозчыларда үз эшләренә җаваплылык хисен тагын да арттырды. Колхозның байлыкларын күбәйтү һәм фронтка продуктларны күбрәк җитештерү өчен артельдә әрмый-талмый эшләү дәрте тагын да үсте. Колхозчы хатын-кызлар фронтка киткән ирләре, агалары, энеләре урынына бастылар. Әсма Шәфикова, Банат Шакировалар үзләрен бик тиз танытырга өлгерделәр. Алар атларны бик оста итеп тәрбияләделәр. Элегрәк транспортта эшләүне «ирләр эше» дип саныйлар иде. Быел Маһи Галиева кебек унган кызлар колхозда алыштыргысыз йөк ташучылар булып әверелделәр. Яки менә һәрберсе 300—500 эр хезмәт көне эшләгән. Г. Дәүләтшин, М. Вәлиева, Ф. Гәрәев, Х. Мөхәмәтҗанова, М. Әхмәтҗанова, Б. Шакироваларны алыйк. Алар эш сайламыйлар, аларны эш сайлый алмый. Ә андыйлар биредә бик күп.

Дөрес, әле бу колхозда артель эше белән исәпләшмичә йөрүчеләр, үз нәфсеЛәренә хуҗа була алмаучылар да юк түгел. Шулардан, мәсәлән, берәү бер начарлык эшли, я ул ындыр табагыннан ашлык урлый, яисә, әйтик, атны имгәткән була. Аның шундый начарлыгын, гаебен күрсәтергә һәм тиешле чараны күрергә кирәк. Ләкин колхоз җитәкчеләре моны эшләмиләр һәм эшли дә алмыйлар. Чөнки аларның үз гаепләре чиктән ашкан: Мәсәлән, председатель Билаловка колхозчы, әлбәттә, әйтә:

—Син үзеңне бел, мин синең кебек хезмәт көне язып, уттай эш өстендә колхозчылардан үземә өй салдырмадым. Мин синең шикелле колхоз эшен өзеп, көне-төне эчеп йөрмим. Син үзең саботаж.

Билаловның көне-төне эчүе авыл советына гына түгел, бәлки район оешмаларына да күптән билгеле. Колхоз дәүләткә ашлык тапшыру планын әле дә үтәмәгән. Ә правление законсыз рәвештә 300 центнердан артык ашлыкны туздырырга өлгергән. Колхозның эчке кирәкләренә закон буенча билгеләнгән 15 процент урынына 30 проценттан артык ашлык тотылган.

Бригадирлар бирелгән нарядны үтәмиләр. Председатель аларга да бер төрле дә йогынты ясый алмый. Чөнки ул үзе алар белән мәҗлестә компаньон.

Шулай итеп, колхоз җитәкчеләре теләсәләр дә, теләмәсәләр дә барлык җитешсезлекләрне аракы сөреме белән каплап калдырырга мәҗбүрләр.

Колхозда әле ашлык сугу да тәгәлләнмәгән. Тамырда вакытта игеннәрнең күренеше буенча һәр гектардан уртача кимендә 12—13 центнер уңыш чыгуы көтелә иде. Вакытында урып-җыйгач колхоздагы сынау участогында ул шулай булды да. Мәсәлән, арышның һәр гектарыннан уртача 15,7 центнер, солының һәр гектарыннан 16,5 центнер уңыш алынды. Урып-җыю һәм ашлык сугуны озакка сузу нәтиҗәсендә, колхозның ярты уңышы җирдә калды. Нәтиҗәдә, сортлы участок белән янәшә һәм бер үк шартлардагы басу арышның һәр гектарыннан бары 7 центнер, солының һәр гектарыннан 8,4 центнер, бодайның һәр гектарыннан бары 1,59 центнер уңыш бирде.

Колхозда исәп-хисап эшләре буталган. Ашлыклар амбарга бөтенләй учетсыз кабул ителгән.

Учетсызлык, иясезлек хөкем сөрү үзенең интересларын җәмәгать интересларыннан өстен куючыларга, ялкауларга колхоз милкен урлауга киң юл ачкан. Үткән җәйнең берничә ае эчендә генә дә тегермәнгә тарту өчен җибәрелгән ашлыкның 75 поты кайтмаган. Дәүләткә ашлык тапшыру вакытында 55 пот ашлык та комга салган су кебек сеңгән. Колхозның моннан башка да бик күп байлыклары әрәм-шәрәм ителә. Менә бер генә факт. Бирелә ел саен 9—10 гектар киндер чәчелә. Колхозда ичмасам бер генә тотам да сүс юк. Чөнки 1941 нче елгы 9 гектар киндер көлтәләре юкка чыккан. Узган елгы киндер көлтәләренең дә күбесе чылатырга салган көе боз астында калдырылган.

Терлекчелек фермаларындагы коточкыч җитешсезлекләр дә югарыда күрсәтелгән сәбәпләр аркасында килеп чыккан. Терлекләргә тиешле шартлар тудырмау, дөрес тәрбияләмәү нәтиҗәсе буларак, аларның продуктлылыгы бик түбән. Моны раслау өчен план буенча һәрбер фуражный сыердан 1.420 литр урынына бары 870 литр сөт алынган булуын күрсәтү дә җитә. Шул ук сәбәпләр буенча 48 баш терлек үлгән. Әле болар исәпкә алынганнары гына. Ә исәпкә алынмаганнары... Аларны ферма мөдире Ярмиева үзе генә белә. Ул яшь терлекләрне туганнан алып 2 айга чаклы керемгә бөтенләй алдырмаган. Сарыкларның да, дуңгызларның да хәзергә кадәр тәгәл учеты юк. Болар барысы да ферма мөдире (шул ук председатель урынбасары да) Ярмиеваның үзенә тапшырылган эштән кул селтәве нәтиҗәсе. Хәер, аның моңа вакыты да юк. Ул тормыш, көн-күрештә череп таралган булуы, азып-тузып йөрүе белән танылган. Колхозчылар аның турында:

— Безнең Ярмиева быел җәй көне генә дә аракы эзләп, колхоз аты белән йөзәр километр җир йөрде,—диләр. Аның да, председатель Билалов шикелле үк, колхозчылар арасында сукыр бер тиенлек тә авторитеты калмаган.

* * *

Билгеле, ВКП(б) ның Шөгер райкомы һәм район советы башкарма комитеты, тикшерү органнары бу колхоз җитәкчеләренә карата кискен нәтиҗәләрне ясарлар. Тагын шуны әйтергә кирәк, авторитет—җитәкчелек өчен иң кирәкле сыйфат. Шуңа күрә, гомумән, бу мәсьәләне принципиаль югарылыкка күтәрергә, хәзерге бурычлар югарылыгыннан төшеп калган, масса арасында авторитетын җуйган, банкротлашкан хәсрәт җитәкчеләрдән Куйбышев исемендәге колхозны арындырырга кирәк.

М. ХӘМИДУЛЛИН.

бит. Мин аларның азатлыгын саклау өчен геройларча көрәшергә, алар өчен яшәргә телим».

Почта һәркөнне фронттан менә шундый, чын мәхәббәт белән тулган хатлар китерә. Әнә фронтовик Рөстәмнең хаты. Ул: «Мин кинәт, почтальонның сиңа хат бар дигән тавышын ишеттем. Кайдан? Кемнән? Мин беркайдан да хат алмый идем бит. Юк, син бу вакытны күз алдына китерә алмыйсың. Сиңа, бу хат өчен рәхмәтемне ничек язып аңлатыйм».

Рөстәм йөрәгенең шатлыгын аңлату өчен сүзләр таба алмый. Аның хатны язучыга сөйлисе сүзләре бик күп:

«Тагын нәрсә языйм сиңа. Немецларның Волокаламскидагы вәхшилекләре турындамы? Анда асылган 8 герой турындамы? Әллә Истра шәһәренең көлләре турындамы? Вертячи хуторындагы коточкыч хәлләр турындамы? Юк, болар турында язуы авыр һәм язып кына аңлатуы кыен».

Барысын да хатта гына ничек сөйләп бетерәсең. Шуның өчен Рөстәм хатны—«Ил өчен, матур тормыш өчен алга, алга!»—дип тәмамлый. Чөнки бу көрәшү көнен якынайта.

Чыннан да, җылы хисләр белән тулган хат йөрәк шатлыгы ул. Йөрәге шат сугышчы үзенең көчен аны шатландыручыга багышлый. Ватан таләп иткәннәрнең барысын да үтәргә әзер тора. Әгәр дә инде, хат туганының эшлексезлеге, сөйгәненнең салкынлыгы турында язылса, яки хат килмичә озак торса, сугышчы күңелсезләнә. Үзләренең сугышчылары турында кайгыртучы командирлар бу мәсьәләдә дә сизгер булалар. Өлкән лейтенант Волков Калинин районының «Комбинат» колхозына, аның члены Гыйлемҗановның 6 айдан бирле семьясыннан хат ала алмавы турында яза. Ул:

— Гыйлемҗанов батыр сугышчы. Ләкин авылдан хат ала алмау аны нык борчый,—ди. Катлаулы хәрби операцияләр белән җитәкчелек итүченең, сугышчысын шатландыру юлын эзләве тылдан килгән хатларның фронтовик өчен никадәр кыйммәт икәнен тагын бер кат раслый.

Менә, бакча баласы—6 яшьлек Эрик. Аның бүләге наводчик Буфинга бирелә. «Иң батыр сугышчыга» дип атап җибәрелгән нәфис кульъяулыгын алгач, фронтовик шатлыгын хат аша, нәни Эрик белән уртаклаша:

«Кадерле Эрик, син тыныч бул. Рәхәтләнеп уйна, көл. Ә мин совет балаларының шат тормышларын саклау өчен батыр сугышырмын» дип нәни дусны ышандыра. Фронтовик Әхмәтов хатында да һәрбер сугышчы тарафыннан әйтелә торган сүзләр кабатлана.

«Хатны бик еш салыгыз. Сезнең хатлар фронтовикларны яңа җиңүләргә канатландыра.

Сез безне күз алдыгызга китерегез. Менә, төн уртасы. Землянкада тимер мич алдында утырабыз. Хатлар укыйбыз, аңа җавап язабыз, җырлар җырлыйбыз. Сез дә фронтка җыр белән кушылыгыз!».

Әйе, ватан сугышы фронтларындагы һәрбер сугышчының йөрәге бер үк уй белән бердәм тибә. Аларның хатлары да, җырлары да матур һәм хисле. Дон буйларын немецлардан азат итеп, көн саен берничә ун километрлар алга баручы частьның шаян сугышчысы Маратның декламацияләрендә орденлы язучы Ш. Маннурның шигырьләре дә яңгырый:

> Мин һәркөнне синнән хат көтәм,
> Күбрәк яз син иркәм, Сәрвәрем.
> Сәламнарың килсен кич-иртән,
> Исеңдә тот, сагыну хәлләрен.

Фронт җырына тыл, фронтның барлык таләпләрен уңышлы үтәгән кебек үк, эшлекле җавап җыры белән кушыла. Совет патриоткасының хатларына:

— Минем җылы хисләрем сине иркәләсеннәр. Авыр походларыңны җиңеләйтсеннәр. Зәһәр салкыннарда сине җылытсыннар. Сине, яңадан-яңа батырлыкларга рухландырсыннар!—дигән сүзләр языла. Бу сүзләрдә эшчән кызларның, шәфкатьле апаларның фронтовикларга булган җылы хисләре чагылдырыла.

М. НУРЕТДИНОВА.

Совет Информбюросыннан

9 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

9 нчы мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Сычевкадан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, оста маневр ясап, халык яши торган зур бер пунктта немецлар гарнизонын чолгап алдылар һәм кырып бетерделәр. Гжатскидан көнбатыштарак совет частьлары, дошманга ударлар ясап, алга киттеләр һәм халык яши торган 20 дән артык пунктны алдылар. Серго-Ивановская тимер юл станциясендә немецларның 5 танкысы, 4 орудиесе, бензин тутырылган күп мичкәләр һәм башка хәрби милекләр безнең кулга төшерелде. Пунктлардан берсендә безнең сугышчылар совет гражданнарыннан 300 кешене азат иттеләр, аларны Германиягә каторгага озату өчен күрше авыллардан гитлерчылар куып китергән булганнар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең разведчиклар дошманның тылына үтеп керделәр һәм немец часовоен плен алдылар. Пленный немецлар частенең штабы урнашкан йортны разведчикларга күрсәтте. Батыр сугышчылар гранаталар ыргытып, штабны шартлаттылар, немецларның бер офицерын, 2 солдатын плен алдылар һәм исән-сау үз частьларына кайттылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть дошманның контратакасын кире кайтарды һәм 100 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк итте. Икенче бер участокта безнең сугышчылар бик каты сугышта бер рота гитлерчыларны тар-мар иттеләр һәм 2 самоход пушка, 9 пулемет, сугыш припаслары төялгән 4 автомашина һәм бер радиостанция кулга төшерделәр. Пленныйлар алынды.

* * *

Льговтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм дошман тарафыннан көчле итеп ныгытылган халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда немецларның бер батальонга якын пехотасы юк ителде һәм 4 танкысы җимертелде. Безнең сугышчылар дошманның бер төзек танкысын экипажы белән берлектә пленга алдылар.

* * *

Украина районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды эсэсчылар подразделениесенә каршы сугышта 50 гитлерчыны кырып ташлаган. Украина партизаннарының икенче бер отряды немецларның берничә тимер юл эшелонының һәлакәтен оештырган. 7 паровоз һәм дошманның җанлы көчләре һәм техникасы төялгән 72 вагон җимертелгән. Бу участокта поездлар хәрәкәте 5 тәүлеккә тукталып торган.

* * *

Итальяннарның «Кунеэнзе» дивизиясенең тыл начальнигы пленга алынган капитан Рао Франческо түбәндәгеләрне сөйләде: «Италиянең армия корпусы Россиядә чынчыннан һәлакәткә дучар булды. Бу корпуста Италия кораллы көчләренең чәчәге җыелган иде. Альп укчылары Италия армиясендә иң чыдамлылар булып саналалар. Ләкин, чигенгән вакытта, Альп полклары тәртипсез төркемнәрне хәтерләттеләр. Солдатлар һәм офицерлар паникага бирелеп качтылар. Рус танклары безнең частьларны бер-берсеннән аердылар һәм таркаттылар. Без тизләтелгән марш белән 18 әр сәгать бардык, ләкин Кызыл Армия безне эләктереп алган кыскычтан ычкына алмадык. Юлда барганда автомашиналарны, коралларны һәм азыкларны ташлап калдырырга туры килде. Бу коточкыч һәлакәт булды. Меңнәрчә итальян солдатларының көнчыгыш фронтта мәгънәсезгә һәлак булуларына немецлар гаепле. Италиядән китәр алдыннан алар безгә, сез Гыйракка, ә аннары Мисырга юл салу өчен Кавказга барасыз, диделәр. Шушының урынына немецлар безне салкыннан саклану өчен берникди средство бирмичә далага ташладылар».

* * *

Берлин радиосы түбәндәге белдерүне тапшырды: «Көнчыгыш фронтның үзәк участогында кайбер урыннарда соңгы көннәрдә көчләрне бер урыннан икенче урынга күчерүнең барышында, Германия гаскәрләре Ржев районында урнашкан халык яши торган Сычевка пунктын эвакуацияләделәр. Эвакуация алдан ук әзерләнелде, һәм ул план буенча, дошман тарафыннан басым булмаган шартларда үткәрелде».

Гитлерчыларның бу ахмак уйдырмаларына ышанырлык җиңел акыллы кешеләр хәзер аз табылыр. Кешеләр инде хәзер Гитлер ставкасының һәм Германия информация бюросының белдерүләрен укырга һәм аңларга өйрәнделәр. Әгәр дә Берлин «көчләрне план буенча күчерү» һәм «фронт линиясен тигезләү» турында хәбәр итә икән, моның немецлар кыйналганнар һәм чигенергә мәҗбүр ителгәннәр, дигән сүз икәнлеген хәзер инде бөтен кеше дә белә. Әгәр дә Берлин, немецлар теге яки бу шәһәрне «дошман тарафыннан басым ясалмаган шартларда» эвакуацияләделәр дип хәбәр итсә, моны совет гаскәрләре гитлерчыларны бу шәһәрдән бәреп чыгардылар, дип аңларга кирәк. Чынлыкта ул Ржевта, Гжатскида һәм Сычевкада шулай булды да. Немецлар Сычевка шәһәрен бик нык сакладылар, алар бу юнәлештә һәм шәһәр өчен булган сугышларда үтерелгән хәлдә генә дә 8 меңгә якын солдат һәм офицерларын югалттылар һәм совет гаскәрләренең басымы астында тәртипсез рәвештә чигенделәр. Немецларның чигенүенең характеры турында совет гаскәрләре тарафыннан кулга төшерелгән трофейлар ук әйтеп торалар. Алар арасында немецларның 310 танкысы бар. Артык та түгел, ким дә түгел.

9 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Шул ук вакыт эчендә дошманның 20.000 нән артык солдат һәм офицерлары үтерелде.

* * *

8 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның 15 кәр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм бер тимер юл составын җимерделәр.

* * *

Гжатскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә дистә пунктны алдылар. Вязьмадан көнчыгыштарак безнең частьлар немецларның каты каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм Темкино тимер юл станциясен һәм район үзәген алдылар. Трофейлар кулга төшерелде. һәм пленныйлар алынды. Күп кенә участокларда гитлерчыларның пехотасы һәм танклары, безнең һөҗүм итүче гаскәрләребезне тоткарларга маташып, берничә тапкыр контратака ясадылар. Бу контратакаларны кире кайтарган чакта немецларның 15 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Халык яши торган Царево-Займище пунктында безнең сугышчылар 1.500 совет гражданын азат иттеләр. Аларны гитлерчылар Германиягә каторга эшләренә куып алып китәргә маташкан булганнар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак дошман танклары һәм пехотасы безнең позицияләргә атака ясадылар. Командиры гвардия лейтенанты Тарасенко булган батареяның артиллеристлары дошманны көчле ут белән каршыладылар һәм немецларның 5 танкысын юк иттеләр. Шулай ук дошманның пехотасы да зур югалтуларга дучар ителде. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары бер ротага якын немец пехотасын кырып ташладылар. Дошманның 3 танкысы сафтан чыгарылды һәм сугыш припаслары төялгән 2 автомашинасы юк ителде.

* * *

Суджадан көнбатыштарак халык яши торган бер пунктта Н-че часть сугышчылары 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар. 6 орудие, 11 пулемет, 5 миномет, төрле йөкләр төялгән 8 автомашина һәм бер радиостанция кулга төшерелде. Икенче бер участокта дошман ротасы контратака ясап караган иде, ләкин безнең пулеметчылар аны бөтенләй юк иттеләр.

* * *

Льговтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманга каршы сугышларда 600 гә якын гитлерчыны юк иттеләр, 13 орудие, 28 пулемет, 4 радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак безнең частьлар немецларның каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм халык яши торган берничә пунктны, шул исәптән Старо-Рамушевоны һәм Ново-Рамушевоны алдылар. Бер баталоннан артык дошман солдатлары кырып ташланды һәм 4 орудие күп кенә пулеметлар, винтовкалар, сугыш припаслары кулга төшерелде.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды февраль ахырында немецларның җәза экспедициясенә каршы сугышта 42 гитлерчыны юк иткән. 3 пулемет, 6 автомашина һәм 21 винтовка кулга төшерелгән. Үз базаларына кайткан чакта партизаннар 5 километр чамасы тимер юлны шартлатканнар. Икенче бер отрядның партизаннары немецларның фронт линиясенә бара торган бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Паровоз һәм 6 вагон җимерелгән.

* * *

Курск өлкәсенең Первое Мая поселогыннан чигенгән чакта немец-фашист кабахәтләр барлык торак йортларны яндырганнар. Кайбер йортларда һәм подвалларда анда булган кешеләр янып яки төтенгә тончыгып үлгән. Шундый юл белән Павел Малеев, аның хатыны һәм өч баласы һәлак булган. Немецлар аларга баздан чыгарга ирек бирмәгәннәр. Колхозчы Андрей Токарев, колхозчы Лепина, аның ике баласы һәм анасы үз йортларында янып үлгәннәр. Колхозчыларның барлык милекләре немецлар тарафыннан талап бетерелгән яки утта янып беткән.

ДОНБАСС — ХАРЬКОВ РАЙОНЫНДА НЕМЕЦЛАРНЫҢ КАРШЫ ҺӨҖҮМЕ

Донбасс районында дошман моннан элекке сугышларда туздырылган һәм җимерелгән 8 танк һәм 5 пехота дивизияләрен тулыландырды һәм күптән түгел Көнбатыш Европадан бу районга ашыгыч рәвештә 12 яңа дивизия, шулардан 4 танк дивизиясе, 1 мотодивизия һәм 7 пехота дивизиясе китерде. Шулай итеп фронтның бу тар участогына немецлар 12 танк дивизиясе, бер мотодивизия һәм 12 пехота дивизиясе, барлыгы 25 дивизия тупладылар.

Февраль ахырында дошман шушы көчләр белән безнең Днепр елгасына таба алга киткән гаскәрләребезгә каршы көчле контратакалар ясады. Немецлар командованиесе, әчкәредән әйләнеп ударлар ясау юлы белән, безнең алга үткән гаскәрләребезне чолгап алырга, юк итәргә һәм Харьков районын кулга төшерергә уйлады. Безнең алгы гаскәри частьларыбыз сан ягыннан өстен булган дошманга каршы каты тоткарлау сугышлары алып барып, командование приказы буенча төньяк-көнчыгышка, Төньяк Донецның төньяк яры районнарына таба вакытында чигенделәр һәм шул вакытта Красноград, Лозовая, Павлоград, Красноармейское, Краматорская, Барвенково, Славянск, Лисичанск шәһәрләрен калдырдылар.

Дошманның һөҗүмне тагын да җәелдерергә, Төньяк Донец елгасын кичәргә һәм Харьковны алырга маташулары безнең гаскәрләрнең каты каршылык күрсәтүенә очрады һәм уңышсыз чыкты. Харьковтан көньятарак һәм көнбатыштарак булган районнарда бик каты сугышлар дәвам итә. Бу сугышлар барышында немец-фашист гаскәрләр гаять күп кешеләрен, техникаларын һәм бигрәк тә танкларын югалталар.

Февраль ахырыннан алып 8 нче мартка кадәр безнең гаскәрләр дошманның 195 самолетын, 650 танкысын, 320 орудиесен, 1.500 дән артык автомашинасын юк иттеләр.

ЛОНДОНДА ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ ХӨРМӘТЕНӘ МИТИНГ

ЛОНДОН, 8 март. (ТАСС). Бөтен Англиядә Халыкара хатын-кызлар көнен бәйрәм итү үткәрелде.

Лондонда күп кеше катнашы белән митинг ясалды. Митингта Англиянең хатын-кызларыннан төзелгән ярдәмче корпуслардан, гражданнар оборонасы отрядларыннан, медицина сестралары группаларыннан күп санда вәкилләр, шулай ук 18 союздаш илләрнең хатын-кызлары тарафыннан җибәрелгән вәкилләр катнашты. Митингта Черчилль ханымның, Рузвельт ханымның, Чан Кай-ши ханымның, Долорес Ибарруриның һәм Людмила Павличенконың котлаулары укылды. Шулай ук Греция хатын-кызларыннан һәм Мальта атавында торучы хатын-кызлардан килгән котлаулар укылды. Митингта катнашучылар фашизмга каршы көрәштә һәлак булган хатын-кызларны аякка басып искә алдылар.

—◇—

Франциянең коммунист-депутатларының мөрәҗәгате

ЛОНДОН, 8 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, кичә Алжир радиосы Франция парламентының күптән түгел Төньяк Африкада төрмәдән азат ителгән 27 коммунист-депутатының мөрәҗәгатен тапшырган. Алар барлык французларны фашизмга каршы көрәшкә берләшергә чакыралар.

Коммунист-депутатлар Төньяк Африкадагы матбугат вәкилләре белән беседа ясаган вакытта түбәндәгеләрне белдергәннәр: «Барлык французларның берләшүләре, Франциянең үлем дошманы булган гитлеризмга каршы көрәштә иң яхшы корал булып тора. Хәзерге вакытта азат ителгәч, бу бердәмлекне без бигрәк тә телибез. Без Францияне бер флаг астында берләштерү өчен бөтен көчебезне бирербез».

—◇—

Америка бомбардировщикларының Руанга һәм Реннга һөҗүме

ЛОНДОН, 8 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 8 нче мартта көндез Американың авыр бомбардировщиклары дошманның Руандагы һәм Ренндагы объектларына һөҗүм ясаганнар.

—◇—

ГЕНУЯНЫҢ ҖИМЕРЕЛҮЕ

ЛОНДОН, 8 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия авиациясенең Генуяга һөҗүмнәре нәтиҗәсендә, барлык порт корылмалары һәм складлар җимерелеп беткән. Шәһәрдә 6.000 нән артык йорт, шул исәптән шәһәр уртасындагы кварталларда 5.000 йорт җимерелгән.

—◇—

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 8 март. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы көчләре штабының хәбәр итүенчә, Тунис фронтының төньяк секторында (Англиянең беренче армиясенә каршы дошманның һөҗүм операцияләре йомшарган. Инглизләр инициативаны үз кулларына алганнар.

Рейтер агентлыгының Төньяк Африкада союзниклар штабы янындагы махсус хәбәрчесенең язуына караганда, Роммель үз кулындагы барлык көчләрдән файдаланып, Англиянең 8 нче армиясенә каршы һөҗүм башлаган.

—◇—

Немецлар нейтраль илләрнең сәүдә пароходларын батыралар

НЬЮ-ЙОРК, 8 март. (ТАСС). Ассошиэйтет Пресс агентлыгының ышанычлы чыганаклардан алып хәбәр итүенә караганда, Германия Швециянең Көнбатыш ярым шарга бара торган сәүдә пароходларын үткәрүдән баш тарткан. Германия барлык нейтраль илләрнең Көньяк Америкага бара торган пароходларын үткәрмәскә карар биргән. Шунлыктан немецлар 24 нче февральдә Испаниянең «Ионте эгельдо» исемле пароходын Монтевидеодан Испаниягә азык төяп барган вакытта батырганнар. Соңгы вакытта немецлар Атлантик океанда Швециянең 3 сәүдә пароходын батырганнар.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт һәм партия тормышы бүлекләре —73—27, типография 36—60.

ПФ 1078 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 403